ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.08.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1558**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль һәм дәүләт милке булган гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зоналарында рекреацион ял итү зоналарын булдыру һәм алардан файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 декабрендәге 3545 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль һәм дәүләт милке булган гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зоналарында рекреацион ял итү зоналарын булдыру һәм алардан файдалану Кагыйдәләрен тәртипкә китерү максатларында, «Һәвәскәри балыгчылык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 декабрендәге 475-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 декабрендәге 3545 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль һәм дәүләт милке булган гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зоналарында рекреацион ял итү зоналарын булдыру һәм алардан файдалану Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 статьяның 12.2. пунктының 2, 3 абзацларында «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р. З. Хаҗиевка Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин